

Мордовиянен торле белем йорты укучылары “Кошларны кышын ашатыгыз!”акциясенә кушылалар.
Акциянен топ максаты - кышлаучы кошларга салкын чорны кичерергә ярдәм итv, шунын белән аларнын санын саклап калу һәм торләрнен торлелеген саклау. Ә бурычлары - кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләv, кышкы авыр шартларда ярдәм итv теләге.
Максат белән бурычларны тормышка ашырып, Темниов районы Аксель мәктәбе укучылары кошларга жим тартмалары ясап, анда аш салып кошларга жинел кышны vткәрергә ярдәм итәләр.
Ромоданово районы Алтар урта мәктәбе укучылары да “Кошларны кышын ашатыгыз!”акциясендә катнаша. Бу мәктәпнен 3 сыйныф укучылары әлеге чарада катнашып кошларны кыш коне жим салып ашаталар.